- **<u>1 нче алып баручы:</u>**
  23 нче февраль… Бу бәйрәмгә инде 94 ел. 94 ел инде кешелекнең иң көчле яртысы көч, түземлелек, патриотизм һәм мәрхәмәтлелек бәйрәмен билгеләп үтә. Нарва һәм Псков янында немец басып алучыларын җину хөрмәтенә 1918 елның 23 февралендә Кызыл Армия көне бәйрәмен билгеләп үтү турында декрет чыгарыла. Соңыннан бу бәйрәм Совет Армиясе һәм хәрби диңгез Флоты көне итеп үзгәртелә. Ә хәзер берничә ел инде Ватанны саклаучылар көне буларак билгеләп үтелә. Россиядә элек-электән үк Ватанны саклаучы иң хөрмәтле һәм изге профессия булып саналган. Ватанга хезмәт итү ул – ул халыкның тыныч тормышын саклау, үз илеңнең намусын саклау.

  “Армия” сүзе латинчадан “коралладырылган” диеп тәрҗемә ителә. Ләкин армия коралы белән генә түгел, ә үзенең кыю, батыр солдатлары белән көчле. 1945 нче елда Совет Армиясе Гитлер гаскәрләрен тар-мар итеп, Европаны фашист илбасарларыннан азат итте.

  Ә тыныч вакытта безнең армия Россиянең унар меңләгән километр коры җир, су һәм һава чикләрен саклый. Һәм һәрвакыт борынгы бабаларыбызның иң яхшы хәрби традицияләренә таяна.

  Алып баручы : Хөрмәтле әтиләр үзегезнең арагыздан 4 кешене сайлап алыгыз . Ә хәзер балаларыгыз белән берлектә ярышта катнашасыз.
- Ә хәзер жюри әгъзалары белән танышып үтегез.
- Балалар бакчасы мөдире :Данилова И.В.
- Тәрбияче: Илюшина Татьяна Анатолиевна
- Ата –аналар комитеты әгъзасы ….
-